МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ
И ИМУЩЕСТВЕННЫХ
ОТНОШЕНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ
МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ
МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

21.02.2013 Казан ш. № 433-р

**Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

1. Тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Министр урынбасарларына, идарә башлыкларына хезмәткәрләрне Регламент белән таныштыруны оештырырга һәм аның тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары С.А.Демидовка йөкләргә.

Министр
А.К.ХАМАЕВ

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
21 февраля 2013 г. N 433-р
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: физик яки юридик затлар, Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрендә урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының милек ияләре (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтә.

1.3.1. Министрлыкның урнашкан урыны: Казан ш., Вишневский ур., 26 й.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00дән 18.00гә кадәр, җомга – 9.00дән 16.45кә кадәр, төшке аш 11.45тән 12.30га кадәр.

Гариза бирүчеләрдән мөрәҗәгатьләр кабул итү: сишәмбе, пәнҗешәмбе 14.00дән 15.00 сәгатькә кадәр.

Җәмәгать транспортында:

1, 4, 25, 43, 69, 71 номерлы автобуслар белән “Калинин” тукталышына кадәр барырга;

метро станциясе – “Сукно бистәсе”.

Пропуск һәм шәхесне раслау документ белән керергә.

1.3.2. Министрлыкның Җир ресурслары идарәсенең җирләрне арендалау һәм реализацияләү бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә алу телефоны: 221-40-39.

1.3.3. Министрлыкның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендәге (алга таба – Интернет челтәре) рәсми сайты адресы: http://mzio.tatarstan.ru.

Электрон почта адресы: mzio@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алып була:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге мәгълүматны эченә алган дәүләт хезмәте турында Министрлык эчендә урнаштырылган мәгълүмат стендларыннан;

2) “Интернет” челтәре ярдәмендә:

Министрлыкның “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтыннан (алга таба – рәсми сайт) (http://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.tatar.ru);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яки телефоннан);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итеп.

1.3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләре турында мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтына һәм, гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Министрлык бинасындагы мәгълүмат стендларына урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге законнар һәм норматив-хокукый актлар нигезендә хәл ителә:

Россия Федерациясе Конституциясе (РФ законнары җыелмасы, 26.01.2009, N 4, ст. 445);

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы (беренче кисәк) (алга таба – РФ ГК 1 к.) (РФ законнары җыелмасы, 05.12.1994, № 32, 3301 ст.) кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ ЖК) (РФ законнары җыелмасы, 29.10.2001, № 44, 4147 ст. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Гражданлык процессуаль кодексы (РФ законнары җыелмасы, 18.11.2002, N 46, ст. 4532);

“Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-биреш итүгә хокукларны дәүләт теркәвенә алу турында” 21.07.1997, № 122-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 122-ФЗ Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 28.07.1997, № 30, ст. 3594) кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында” 25.10.2001, № 137-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 137-ФЗ Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 29.10.2001, № 44, 4148 ст. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне приватизацияләү турында" 21.12.2001 N 178-ФЗ (РФ законнары җыелмасы, 28.01.2002, N 4, ст. 251);

Күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастры турында” 24.07.2007, № 221-ФЗ Федераль закон (РФ законнары җыелмасы, 30.07.2007, № 31, 4017 ст.);

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында” 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 02.08.2010 ел, № 31, 4179 ст.);

Россия Федерациясе икътисади үсеш министрлыгының "Җир кишәрлегенә хокук алу өчен кирәкле документлар исемлеген раслау турында" 13.09.2011 N 475 боерыгы (алга таба - Боерык N 475) (Российская газета, N 222, 05.10.2011);

Татарстан Республикасы Конституциясе (Республика Татарстан, N 87-88, 30.04.2002);

Татарстан Республикасы Җир кодексы (алга таба – ТР ҖК) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 16.02.2005, N 7);

"Татарстан Республикасында дәүләт милкен приватизацияләү турында" Татарстан Республикасының 26.07.2004 N 43-ЗРТ Законы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 11.08.2004, N 29-30, ст. 3126);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир өчен аренда түләве турында» 1995 елның 9 февралендәге 74 номерлы карары (Известия Татарстана, 14.02.1995, № 28);

“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 05.12.2005 ел, № 563 карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламенты (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 21.12.2005, № 47-48, 0985 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре” 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 03.10.2007, № 37, 1379 ст.);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 880 ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, 2144 ст.);

“Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында” 13.08.2011, № 675 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 19.10.2011, № 39, 1928 ст.);

«Россия Федерациясе Җир кодексының 39.20 статьясы белән күздә тотылган очракларда Татарстан Республикасы милкендәге яки аларга карата дәүләт милке чикләнмәгән, аларда биналар, корылмалар урнашкан җир кишәрлекләрен мондый биналар, корылмалар йә алардагы бүлмәләр милекчеләренә сату турында» 03.10.2012 № 827 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары. (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 09.10.2012, № 75, 2474 б.).

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләпнең эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү | РФ ГК; РФ ЖК; Федераль закон № 137-ФЗ; ст. ст.4,18 ТР ҖК п. 3.3.19 Нигезләмә |
| 2.2. Башкарма хакимиятнең дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче органы атамасы | Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | п. 3.3.19 Нигезләмә |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы | Җир кишәрлеген юридик яки физик затка арендага бирү турында Министрлык карары.<br>Җир кишәрлеген юридик яки физик затка милеккә бирү турында Министрлык карары.<br>Җир кишәрлеген милек итеп яисә арендага бирүдән баш тарту | ст. 36 ЗК РФ; ст. ст. 30, 48 ЗК РТ |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы | Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать кергәннән соң бер ай эчендә күрсәтелә | РФ ҖК 36 ст. |
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук гариза | Җир кишәрлегенә хокуклар алу өчен гариза бирүче гариза (1 нче | РФ ҖК 36 ст. Боерык N 475 |

| | | |
|---|---|---|
| бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | кушымта) белән бергә түбәндәгеләрне тапшыра:<br><br>1. Физик зат булган гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең), яисә физик яки юридик зат вәкиленең шәхесен раслаучы документ күчермәсе.<br><br>2. Гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, физик яки юридик зат вәкиленең хокукларын (вәкаләтләрен) раслаучы документ күчермәсе.<br><br>3. Гариза бирүченең ала торган җир кишәрлегендә урнашкан бинага, корылмага хокукын раслаучы (билгеләүче) документ күчермәләре, әгәр дә Россия Федерациясе законнары нигезендә аның бинага, корылмага хокуклары Күчемсез милек һәм аның белән алыш-бирешкә хокуклар бердәм дәүләт реестрында (алга таба - ХБДР) теркәлүенә бәйсез рәвештә барлыкка килгән дип танылган булса.<br><br>4. Гариза бирүченең ала торган җир кишәрлегенә хокукын раслаучы (билгеләүче) документ күчермәләре, әгәр дә Россия Федерациясе законнары нигезендә аның хокуклары Күчемсез милек һәм аның белән алыш-бирешкә хокуклар бердәм дәүләт реестрында (алга таба - ХБДР) теркәлүенә бәйсез рәвештә барлыкка килгән дип танылган булса. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 5. Җир кишәрлеген алырга хокук бирүче шартларны раслаучы документ күчермәсе, шулай ук, аерым шартларда, ҳаими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез вакыты чикләнгән, милеккә яки арендага җир законнары белән белгеләнгән шартларда, әлеге шарт әлеге Исемлекнең 3 – 4 пунктларында күрсәтелгән документлардан булмаса.<br><br>6. Гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) соралган җир кишәрлегендә урнашкан бөтен биналар, корылмаларның, кадастр номерлары (шартлы, инвентарь) һәм адрес ориентирлары күрсәтелгән исемлеге җир кишәрлеге бирү турында мөрәҗәгатьнең тәкъдим ителгән кушымтасындагы формада бирелгән белдерүе.<br>Гаризага беркетелгән документларның күчермәләре нотариуста раслана ала. Нотариаль расланган күчермә булмаганда түбәндәгеләр дә кабул ителә ала:<br>- җитәкче яки вәкаләтле вазыйфаи зат имзасы һәм оешма мөһере белән дөреслеге расланган документ күчермәләре;<br>- документның оригиналы күрсәтелсә, расланмаган күчермәләр. Бу очракта докуиентларны кабул итеп алучы күчермәне оригинал белән чагыштыра. | |
| 2.6. Норматив хокукый актларга туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм башка оешмаларда саклanган, гариза | Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына: | РФ ҖК 36 ст. Боерык N 475 |

| | | |
|---|---|---|
| бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар саклнган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | 1. Физик затның шәхси эшмәкәр булып дәүләт регистрациясе узуы турында таныклык күчермәсе (шәхси эшмәкәрләр өчен), юридик затның дәүләт регистрациясе узуы турында таныклык күчермәсе (юридик затлар өчен) яки бердәм дәүләт реестрыннан җир кишәрлегенә хокуклар алу өчен гариза бирүче булган юридик зат яисә шәхси эшмәкәр турында өземтә.<br><br>2. Алынучы җир кишәрлегендә биналар, корылмаларның урнашса – алынган җир кишәрлегендә урнашкан бинага, коралмага хокуклар турында ХБДР өземтәсе, яки күрсәтелгән бинага, корылмаларга хокуклар теркәлүе турында соралган белешмәләрнең булмавы турында ХБДР хәбәре.<br><br>3. Алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында ХБДР өземтәсе яисә ХБДРда күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар булмавы турында ХБДР хәбәре.<br><br>4. Соралган җир кишәрлегенең кадастр паспорты яисә соралган җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе, әлеге җир кишәрлегенә хокуклар алу өчен гариза хокукларны яңадан теркәү максатыннан бирелгән булса | ТР МКның N 675 карары |

| | | |
|---|---|---|
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителгән һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма орган тарафыннан тормышка ашырыла торган норматив-хокукый актларда каралган очракларда килештерү зарури булган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тулы комплекты беркетелмәгән.<br><br>2. Гаризада һәм (яки) аңа беркетелгән документларда төрлечә аңлауга китерүче чистартулар, өстәп язулар булу (гариза һәм аңа берткетелгән документлар Бүлеккә турыдан туры тапшырылган очракта) | РФ ҖК 36 ст. Боерык N 475 Постановление<br><br>КМ РТ N 675 |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законнарда каралмаган<br>Основания для отказа в представлении государственной услуги в общих случаях:<br>Гомуми очракларда дәүләт хезмәте күрсәтдән баш тарту өчен нигезләр:<br><br>1. Гариза бирүче тапшырган документларда дөрес булмаган мәгълүмат булу.<br><br>2. Җир кишәрлеге дәүләт милке түгел. | РФ ҖК ст. ст. 27, 28, 36, 56.1 ст. Боерык N 475 |

| | | |
|---|---|---|
| | 3. Бирелгән документлар әлеге Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килми.<br><br>4. Дәүләт хезмәте алу өчен вәкаләте булмаган кешенең мөрәҗәгате.<br>Җир кишәрлекләрен милеккә бирү өчракларында дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен:<br><br>5. Җир кишәрлекләре әйләнештән алынган җирләргә керә.<br><br>6. Җир кишәрлекләре әйләнеше чикләнгән җирләргә кергән, аларны хосусый милеккә бирү федераль законнар белән билгеләнмәгән.<br><br>7. Җир кишәрлекләре яр буе полосасы чикләрендә урнашкан.<br><br>8. Җир кишәрлекләре гомуми куллану территорияләре чикләрендә урнашкан һәм аларда буалар, сулы карьерлар бар.<br><br>9. Җир кишәрлекләре дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗ өчен резервта тора. Гариза һәм аңа беркетелгән документларны почта аша биргәч.<br><br>10. Документлар расланмаган, мөһер сугылмаган, законнарда билгеләнгән вазыйфаи затларның имзасы юк.<br><br>11. Документларның тексты танылмаслык итеп язылган, юридик зат атамалары кыскартып бирелгән, урнашкан урыны күрсәтелмәгән.<br><br>12. Документларда чистартылган, өстәп язылган урыннар бар, сүзләр сызылган, алдан килештерелмәгән төзәтүләр кертелгән.<br><br>13. Документлар карандаш белән тутырылган | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы алынучы түләүләрнең тәртибе, күләме һәм нигезләре, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри дәүләт хезмәтләре түләүсез күрсәтелә. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы | Дәүләт хезмәте алучының (гариза бирүченең) кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүенең һәм дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап гариза бирүченең запросын рәсмиләштерү срогы | Мөрәҗәгать һәм документлар кергән көндә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә таләпләр | Мөрәҗәгать Министрлыкка 420043, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. адресы буенча бирелә (юллана).<br>Дәүләт хезмәтләре күрсәтелү тиешле күрсәткечләр белән җиһазланган бүлмәләрдә башкарыла.<br>һаваны суыту-җылыту системасы; янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы; | |

| | | |
|---|---|---|
| | документлар тутыру өчен җиһаз;<br>Татарстан Республикасы Дәүләт интеграцияләнгән телекоммуникация системасына тоташтырылган мәгълүмати киоск;<br>мәгълүмати стенд.<br>Дәүләт хезмәте күп функцияләр башкаручы үзәктә күрсәтелми. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре | Дәүләт хезмәтенең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>- документларны кабул итү һәм карау срогының саклануы;<br>- Регламентның дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан бозылуын күрсәткән очракларның (нигезләнгән шикаятьләрнең) булуы (очраклар, шикаятьләр санының хезмәт күрсәтүче Министрлык белгечләренең гомуми санына чагыштырмасы).<br>Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>- Министрлык биналарының җәмәгать транспортына якын булуы;<br>- кирәк кадәр санда белгечләрнең, шулай ук, гариза бирүчеләрнең документларын кабул итә торган урыннарның булуы;<br>- мәгълүмати стендларда һәм “Интернет” челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе һәм вакыты турында тулы мәгълүмат булу | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтелми | |

--------------------------------

<1> Киңәш ителгән форма.

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларның (гамәлләрнең) электрон рәвештә үтәлүе үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы

3.1.1. Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм регистрация;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау;

4) Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү турында карар әзерләү һәм кабул итү, яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр әзерләү, шул исәптән:

5) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 4 нче кушымтада китерелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү.

Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Бүлеккә шәхсән, телефоннан, һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итүгә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә тапшырылырга тиешле документларның составы, формасы ягыннан һәм дәүләт хезмәте алуга карата башка мәсьәләләр буенча консультация бирә

Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: биреләсе документациянең составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация.

3.3. Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү, яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту

3.3.1. Гариза бирүче (аның вәкиле) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар беркетелгән мөрәҗәгатен Бүлеккә бирә (юллый) яки күрсәтелгән документларны почта аша юллый.

3.3.2. Бүлек белгече гариза һәм документлар Бүлеккә тапшырылса:

мөрәҗәгатьне һәм документларны кабул итә;

гариза бирүченең шәхесен ачыклый, шәхесне ачыклый торган документны тикшерә; вәкилнең вәкаләтләрен (боерык, ышанычнамә һ.б.) тикшерә;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерә, түбәндәгеләрне ачыклый:

- документлар расланган, мөһер сугылган, законнарда билгеләнгән вазыйфаи затларның имзасы бар;

- документларның тексты таныклык итеп язылган, юридик зат атамалары кыскартмыйча бирелгән, урнашкан урыны күрсәтелгән;

- документларда чистартылган, өстәп язылган урыннар юк, сүзләр сызылмаган, алдан килештерелмәгән төзәтүләр кертелмәгән;

- документлар карандаш белән тутырылмаган;

- документларда аларның эчтәлеген төрлечә аңларга мөмкинлек бирә торган зарарланган урыннар юк.

Гариза бирүченең документ күчермәләре расланмаган булса, әлеге күчермәләр тапшырылганда төп нөсхә дә күрсәтелә һәм алар Бүлек белгече тарафыннан раслана.

Гариза бирүче документларның тулы комплектын тапшырмаса, шулай ук, техник хаталар булган яки аларны формалаштыру алда күрсәтелгән таләпләргә туры килмәсә, Бүлек белгече дәүләт хезмәтен гамәлгә ашыру өчен каршылыклар булуын хәбәр итә, тапшырылган документларда ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, документларда ачыкланган җитешсезлекләрне төзәтү максатыннан чаралар күрү өчен кире кайтара.

Бүлек белгече бирелгән документларны тикшергәч түбәндәгеләрне башкара:

Документлар кабул ителү турында яисә кабул итүдән баш тарту турында гаризаларны исәпкә алу кенәгәсенә язып куя (язуының тәртип номеры, кабул итү датасы һәм минутына кадәр төгәллек белән вакыты, документларның гомуми саны, гариза бирүче турында мәгълүмат, гариза бирүченең мөрәҗәгате максаты, документларны кабул итүдән баш тарту сәбәбе, үз фамилиясе һәм инициаллары);

Гаризага теркәлгән документларның исемлеген формалаштыру (җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гаризага 2 нче кушымта), шунда ук документлар

кабул иткән һәм гариза бирүчеләрне теркәп кую кенәгәсенә язган белгечнең фамилиясе һәм инициаллары күрсәтелә, имзасы куела;

Министрлыкта җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гаризалар үтү битен (2 нче кушымта) тутыра;

Гариза бирүчегә гаризага теркәлгән документлар исемлегенең беренче экземплярын бирә;

гариза үтү бите белән бергә гаризаны һәм документларны һәм гаризага теркәлгән документлар исемлегенең икенче экземплярын регистрация өчен Министрлыкның эш башкару һәм контроль бүлегенә (алга таба – эш башкару бүлеге) юллау.

Процедураның нәтиҗәсе: тикшерелгән һәм эш башкару бүлегенә юлланган гариза һәм документлар; документларны кабул итүдән баш тарту.

3.3.3. Эш башкару бүлеге белгече Бүлеккә гариза һәм аңа беркетелгән документлар кергәч, шулай ук, алар почта буенча килгәч, кергән гаризаны һәм документларны регистрацияли, керү номеры суга һәм кару өчен Бүлеккә юллый.

Әлеге Регламентның 3.3.2 - 3.3.3 пунктлары билгели торган процедуралар мөрәҗәгать һәм документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Әлеге Регламентның 3.3.3 пункты билгели торган процедура мөрәҗәгать һәм аңа беркетелгән документлар почтадан алынган көнне гамәлгә ашырыла (мөрәҗәгать һәм аңа беркетелгән әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар почтада аша юлланган очракта).

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Бүлеккә юлланган мөрәҗәгать.

3.3.4. Бүлек белгече ведомствоара ведомоствоара электрон арадашлык системасы аша электрое запрослар юллый:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннаняисә шәхси эшмәкәрләр бердәм дәүләр реестрыннан мәгълүмат бирүне сорап Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә (алга таба – ФСХ ТРИ);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенә (алга таба – Росреестр ТРИ) – алынасы җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, бинадагы бүлмәгә хокук турында (күрсәтелгән бинага, корылмаларга теркәлгән хокуклар турында мәгълүмат булмавына ХБДРдан өземтә) бирү турында;

ТР буенча Росреестрга соралган җир кишәрлегенә хокуклар турында ХБДРдан өземтә бирү турында (күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар булмавы турында ХБДРда белешмә булмавы турында хәбәр) ;

«Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына (алга таба – ТР Росреестр) соралган җир кишәрлегенең кадастр паспортын бирү турында.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң өч көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүматлар (документлар) бирү турындагы запрослар

3.3.5. Бүлек белгече ФСХ ТРИ, ТР Росреестрдан соралган белешмәләр алынганч түбәндәгеләрне башкара:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булуын тикшерә;

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен күчемсез милек объектларының милек ияләренә – физик яки юридик затларга арендага яки милеккә бирү турында карары проектын (алга таба – арендага яки милеккә бирү турында карар проекты), яисә гариза бирүче китергән документлар буенча җир кишәрлеген биреп булмау аңлатылган һәм ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү тәкъдимнәре булган арендага яки милеккә бирүдән баш тарту турында хәбәр проекты (алга таба – баш тарту турында хәбәр) әзерләнә;

арендага яки милеккә бирү турында карары проектын, яисә баш тарту турында хәбәр проектын килештерү өчен Бүлек мөдиренә юллау.

Җир кишәрлеге әһләнештән алынган һәи әйләнеше чикләнгән булса, милеккә бирүдән баш тарту турында хәбәрне, шулай ук җир кишәрлеге әйләнештән алынган булса аны арендлага бирүдән баш тарту турында хәбәрне 3 нче кушымта буенча формалаштырырга.

Күрсәтелгән хәбәрләр әлеге Регламентның 2.9 пунктында китерелгән башка очракларда да формалаштырыла.

Бу пункт билгели торган процедуралар запросларга җаваплар алынганнан соң дүрт көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек мөдиренә юлланган арендага яки милеккә бирү турында карары проекты, яисә баш тарту турында хәбәр проекты.

3.3.6. Бүлек мөдиренә юлланган арендага яки милеккә бирү турында карары проектын яисә баш тарту турында хәбәр проектын карап чыга, килештерә һәм килештерү өчен җир ресурслары идарәсе (алга таба – Идарә) башлыгына юллый.

3.3.7. Идарә башлыгы арендага яки милеккә бирү турында карары проектын яисә баш тарту турында хәбәр проектын карап чыга, килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге Регламентның 3.3.6, 3.3.7 пунктлары билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң дүрт көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек мөдире, Идарә башлыгы белән килештерелгән арендага яки милеккә бирү турында карары проекты, яисә баш тарту турында хәбәр проекты.

3.3.8. Бүлек белгече Бүлек мөдире, Идарә башлыгы белән килештерелгән арендага яки милеккә бирү турында карары проектын, яисә баш тарту турында хәбәр проектын хокукый экспертиза үткәрү өчен хокук идарәсенә юллый.

Бу пункт билгели торган процедуралар Министрлык карары проектын яки баш тарту хәбәре проектын Идарә башлыгы килештергән көн эчендә үтәлә.

